**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-57-77
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-57-77
факс: 8-(84378) -2-50-62

№43 2019 елның 22 апреленнән

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы**
**Лаеш шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш**
**Кагыйдәләрен әзерләү буенча**
**комиссия булдыру турында**

Кешенең уңайлы тормыш эшчәнлеге шартларына хокукларын үтәү шартларын булдыру, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре территориясендә урнашкан җир участоклары һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүмаксатыннан, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына, 2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга ярашлы төстә, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен әзерләү буенча комиссия булдырырга һәм аның составын расларга (1нче кушымта). Аның компетенциясенә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты турында фикер алышу, шул исәптән аларга үзгәрешләр кертү, планировка проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, җир участокларыннан яки капиталь төзелеш объектларыннан файдалану төрен шартлы рөхсәт ителгән булуына рөхсәт бирү һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләү параметрлары чикләреннән тайпылуга рөхсәт бирү турында мәсьәләләрне карау буенча ачык халык тыңлаулары оештыру һәм үткәрү керәчәк.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен әзерләү буенча комиссия турында кушып бирелүче Кагыйдәне (2нче кушымта) расларга.
3. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Җитәкче** **Р.Р.Нургалиев**